СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

23.04.2026

Алабуга шәһәре

№ 61

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында.

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы һәм Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы:

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Муниципаль хезмәт вазифаларын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 2026 елның 30 мартындагы 54 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары

А.В. Косов